БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15 декабрь 2022 ел № 163

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына генераль планнарын әзерләү кирәк булмау турында карарлар кабул ителгән авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан торак пунктлар чикләре турында белешмәләрне өстәү өлешендә үзгәрешләр кертү проектын раслау хакында**

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясен шәһәр төзелеше планлаштыруын гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14,15 статьяларына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставына таянып, гавами тыңлаулар һәм килештерү комиссиясе нәтиҗәләре буенча, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына генераль планнарын әзерләү кирәк булмау турында карарлар кабул ителгән авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан торак пунктлар чикләре турында белешмәләрне өстәү өлешендә үзгәрешләр кертү проектын расларга.

2. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына:

- әлеге карарның 1 пункты белән расланган территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проекты нигезендә шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашырырга;

- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына генераль планнарын әзерләү кирәк булмау турында карарлар кабул ителгән авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан торак пунктлар чикләре турында белешмәләрне өстәү өлешендә үзгәрешләр кертү проектын раслау турында карарны Территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасына урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны baltasi.tatarstan.ru Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р.Нотфуллин